СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы**
**карары**

**« 24 » апрель 2023 ел** **№ 72**

**«Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәне раслау хакында» Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2022 елның 24 октябрендәге 60 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законга, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Арча муниципаль районы "Яңа Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының «Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 24 октябрендәге 60 номерлы карары белән расланган Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1.1. «3. Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе) депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне срогыннан алда туктату өчен нигез туган көн булып әлеге гаризаның Яңа Кырлай авыл җирлеге Советына кергән көн тора.»;

1.2.18 статьяның 1 пунктының б пунктчасы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында оештырылган беренчел профсоюз оешмасының сайлап куелган органы, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәте съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашудан тыш) Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә алдан хәбәр итеп;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров